**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Әгерҗе авыл җирлеге Советы**
**карары**

Әгерҗе авылы № 179-83 15 июнь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты хакында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертү белән бәйле

Әгерҗе авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектын кабул итәргә:

2. Әлеге карарны, 2020 елның 20 июненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенч аурнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http:// aznakyevo.tatarstan.ru, Әгерҗе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. 2020 елның 22 июлендә 17.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авылы, Г.Әхмәтова урамы, 14а йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, ачык ыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин:Әгерҗе авылы, Г.Әхмәтова урамы, 14а йорты

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем төзергә:
- Хәсәнов Назыйф Нилович - Әгерҗе авыл җирлеге башлыгы;
- Гәрәйшин Нәсим Рәсимович - Әгерҗе авыл җирлеге депутаты;
- Фахуртдинов Миргаяз Масавихович- Әгерҗе авыл җирлеге депутаты.

6.Ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әгерҗе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне,гражданнарны кабул итү, исәпкә алуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссия халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне

исәпкә алып карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис: Н.Н.Хәсәнов

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советы карарына 1 нче кушымта
«15» июнь 2020 № 179-83

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 34 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Әгерҗе авыл җирлеге" муниципальберәмлегеУставына(24.09.2012 №48, 05.08.2013 № 69, 22.10.2014 №103, 30.09.2015 № 3, 15.11.2016 № 39-16, 17.04.2018 № 93-41, 03.09.2018 № 108-50, 05.11.2019 № 154-71 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәләр кертергә:

1.1. 6 статьяның 1 өлешендәге 9.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1.) Россия Федерациясе граждан законнары игезендә үз белдеге белән төзелешне сүтү, үз белдегең белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерүтурында карар кабул итү;».

1.2. 29 статьяның 6 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты хокуклы түгел:

1) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш, коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу (конференция), Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президентының алдан хәбәрнамәсе нигезендә катнашу;

в) «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы» Ассоциациясендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлекнең идарә органнарында һәм Ревизия комиссиясендә, гамәлгә куючы (акционер) булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) мәнфәгатьләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә

куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектә булган
акцияләр (устав капиталында өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган
муниципаль хокукый актлар нигезендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, мөгаллимлек, фәнни һәм
3) башка ... Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка

башка иҗади эшчәнлектән тыш. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка
иҗади эшчәнлек бары тик чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары,
чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына
финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яки
Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаган булса;

4) идарә органнары, попечительлек яки күзәтчелек советлары, Россия
Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган
хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына, әгәр Россия
Федерациясенең халыкара килешүендә яки Россия Федерациясе законнарында
башкасы каралмаган булса, керергә.».

1.3. 47 статьяның 1 өлешендәге дүрт абзацны түбәндәге редакциядә бәян
итәргә:

«-Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән
төзелгән корылманы сүтү, үз белдегең белән корылган корылманы сүтү яки аны
рәхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары, яисә федераль
законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри
таләпләр белән тәңгәлләштерү турында карарлар кабул итә;»

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен
җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы
хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча
урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль
районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге
веб-адрес буенча: http:// aznakyevo.tatarstan.ru һәм Әгерҗе авыл җирлегенең
мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе,
депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә
йөкләргә.